**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Килдеш авыл җирлегенең Килдеш торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**05 декабрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Килдеш авыл җирлегенең Килдеш торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең Килдеш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, локаль хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Килдеш авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Килдеш авылы зираты коймасын төзекләндерү;
- Килдеш авылында урамнарны яктырту өчен лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;
- Килдеш авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **В.С. Исаев**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Килдеш авыл җирлеге башлыгы** **В.С. Исаев**